ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

25.11.2019 | с. Русское Макулово | 06

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең
Исаево авылында гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 10 декабренә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Исаево авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге Исаево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризалыгыгыз бармы:

- Исаево авылында җирле әһәмияттәге юлларны ремонтлау

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Исаев урамы, 24 нче йорт янында 12.00 сәгатьтә уздырырга.

4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын халык җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге
Башлыгы А.И. Матвеева